


Момкинлекләре чикле кешеләргә яр-дәм итv - Мордовиядә 3 декабрьдән 12 декабрьгә кадәр уза торган Инвалидлар декадасынын топ максаты. Унконлек кысаларында инвалидлар очен торле чаралар, хәйрия кичәләре һәм концертлар vткәрелә.
«Момкинлекләре чикләнгән кешеләр тулы канлы тормыш белән яшәргә, спорт белән шогыльләнергә, ижади конкурсларда катнашырга тели», - ди Анна Базаева. Мәгариф отличнигы, ул гомеренен 14 елын Темниково балалар интернат-йорты балаларына багышлаган.
Педагог «Темниковские известия»гә биргән хатирәләрендә болай ди: «Язмыш мине балалар йорты белән бер генә тапкыр бәйләмәде. Сугыштан сонгы авыр вакытта әтием Темников балалар интернат-йортында эшләде, - дип сойли Анна Ильинична. - Безнен гаиләгә интернатнын мунча ишегалдында-предбанникта яшәргә рохсәт иттеләр. Хәтерлим әле, мунча коннәрендә балалар йортында эшләvче хатын-кызлар су ташыганда, бездә бик салкын иде, без юрган астына яшеренә идек».      Тормыш vз чираты белән барды. Без балалар йортыннан килгән балалар белән дус булдык: бергәләп уйнадык, кинога йордек. Биредә сугыш вакытында ятим калган балалар тәрбияләнә иде. Соныннан безнен гаиләгә Сталин исемен йорткән балалар йортынын подвал бинасында фатир бирделәр. Берничә елдан әтине кыскарттылар, һәм безнен гаилә Старый Шукстелимгә китәргә мәжбvр була. Мин югары сыйныфларда укыдым, шуна кvрә Темникта калдым. Башта бер абый янында, аннары икенчесендә яшәдем. Кvп укыдым, яхшы укырга тырыштым, югары белем турында хыялландым. 1968 елда педагогия институтын тәмамладым. Монын очен бик кvп кыенлыкларны жинәргә туры килде, бигрәк тә матди яктан. Энем Иванны армиягә озат канда, китәр алдыннан ул мина унбер сум бирде. Мин бәхеттән «жиденче кvктә» булдым! Шунын беразына vземә кием сатып алдым. Мин бик тырышып, стипендиягә укыдым, шуна кvрә кечкенә генә очлек алырга да vземә рохсәт итә алмадым».
Педагогик институтны тәмамлаганнан сон, Анна Ильинична 13 ел Канаково укучыларын немец теленә ойрәтә, аннары 3 ел Темниково район мәгариф бvлегендә хезмәт укыту буенча инспектор, 8 ел - балачак хокуклары буенча инспектор булып эшли. Узган гасырнын 90 нчы елларында, лаеклы ялга чыкканчы, хезмәт куйган балалар йортына олкән тәрбияче булып кvчкән.
Темников балалар интернат-йорты узган гасырнын 30 нчы еллар уртасында ачылган иде. Анда физик яктан тайпылышлар аркасында әти-әниләре нарасыеннан баш тарткан балалар тәрбияләнгән. Башта алар, оч яшькә кадәр Бала йортында тәрбияләнгән, ә

аннан сон Темников балалар интернат - йортына элэгэ.
«Мин балалар йортында эшлэгэн елларда 50шэр, 70эр бала булды. Аларга ата-аналарын тэрбиячелэр, медицина һэм хезмэт кvрсэтvче персонал алмаштырды: туган коннэрен билгелэп vттелэр, бэйрэмнэр, танып - белv викториналары һэм кvнел ачу концертлары оештырдылар, - дип искэ ала балалар белэн эшлэv елларын А.И.Базаева. - Без Ф.Ф.Ушаков исемен йорткэн туган якны ойрэнv музеена бара идек, мэдэният йортындагы концертларга. Саранскка, мэсэлэн, Степан Эрьзя скульптуралары кvргэзмэсенэ, Саровка - Изге Серафимга экскурсиялэр белэн йордек. Безнен спонсорлар - ВНИИЭФ хезмэткэрлэре бик жылы каршы ала торган иде. Аларнын һэркайсынын vз тэрбиялэнvчесе бар иде, аларга бvлэклэр тапшырдылар. Шул вакыт балалар бик тэ бэхетле булалар! Эмма балалар йортында аларны ничек кенэ яхшы карамасалар да, ата-аналы булырга һэрвакыт телэделэр. Тэрбиялэнvчелэр телевизордан «Кот ми-не» тапшыруын карарга яраттылар. Бигрэк тэ Игорь Кваша алып барган вакытта аларга ошады. Балалар, эти-энилэрен тапкан бэхетле балаларны кадерлэп карый торган иделэр».
Балалар йортында тэрбиялэнvчелэр, бигрэк тэ чыгарылыш сыйныф укучылары, эти-энилэрен табу очен, олкэн тэрбиячегэ морэжэгать итэлэр. Анна Ильинична да аларны эзлэп таба, хатлар яза, ботен Россия буенча запрослар жибэрэ, жаваплар ала. Аннары аларнын йорэклэренэ барып житэргэ тырыша. Эти-энилэренен балаларына бик кирэк икэнен анлатасы килэ. Шатлык очраклар да булды, кайчагында бу момкин тумый да иде.
Беренче бэхетле Андрей Кравцов булды. Анын эти-энисе Амур олкэсендэ яшэгэн һэм улларынын исэн булуын белмэгэн. Алар очен бу шок булды. Мэктэпне тэмамлаганнан сон Андрейны Потьмага кадэр озаттылар, поездга утырттылар, э шэһэрдэ аны эти-энилэре каршы алды.
Тагы Женя А. vтенече буенча, энисен эзлэп таптык. Ул Саранскида яши һэм хэзер алар аралаша. Шулай Аня Хайко Тvбэн Новгородта яшэгэн абыйсын эзлэп таба. Юлия Савостикова Красноярск краенда яшэvче сенеллэрен тапты. Ел саен Юля алар янында була. Татарлар очен хас булмаган очрак турында да хэбэр: Эльвира Знын энисе Казанда яши һэм кызы эзлэве турындагы хатка болай дип жавап биргэн: нигэ аны борчыйлар, ул бит баласыннан баш тарткан кэгазь язган булган... Аннан аралашу барыбер булган, эмма телэгэнчэ жылы булмаган. Володя И. очен дэ туганнары табылган. Беренче кичтэ алар кем икэнлеклэрен ача алмый. Э иртэн Володя аларнын оныклары булу турында сойлэргэннэр. Эби-бабай оныкларынын энисе исэн, эмма аны борчырга кирэкми, дигэннэр - анын яна гаилэсе һэм уллары бар. Мэктэпне тэмамлаганнан сон Володя инвалидлар очен интернатка китэ, чонки аны берэv дэ оенэ алмый; ике тапкыр туганнары аннан баш тарта.
«Хочется пожелать всем детям в семьях и детских домах отзывчивых взрослых, - говорит напоследок А. И. Базаева. - Чтобы и родители, и воспитатели любили их, дарили им только радость и добрые слова».
Без, ярдэмгэ мохтажларга, билгеле коннэрдэ генэ тvгел, э һэрвакыт ярдэм итv турында онытмаса идек.

**Н.ХӘЛИЛ** әзерләде